Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге составындагы  Борок торак пунктында үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2022 елның 30 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенигезендә, 2022 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлегенең Борок торак пунктында үткәрелгән «Гражданнарның үзара салым җыю турындагы» гражданнар җыены буенча кабул ителгән 2020 елның 25 ноябренең №2 «Гражданнарның үзара салымга җыелган  131550 сум акчаны Борок авылында янгын сундеру машинасы өчен гараж төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), зиратны төзекләндерүгә (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) юнәлтергә»

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 334 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 172 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 172 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыдагы нәтиҗәләрдән чыгып, гражданнар җыены карары:

1.Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге составындагы  Байгол торак пунктында гражданнар җыенын узган дип , гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2022 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлегенең Борок торак пунктында үткәрелгән «Гражданнарның үзара салым җыю турындагы» гражданнар җыены буенча кабул ителгән 2020 елның 25 ноябренең №2 «Гражданнарның үзара салымга җыелган 131550 сум акчаны Борок авылында янгын сундеру машинасы өчен гараж төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), зиратны төзекләндерүгә (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) юнәлтергә» дигән карары белән “килешү”(ӘЙЕ), “килешмәү”(ЮК)” карарын- дөрес дип танырга.

3. Мәгълүмат стендларында, Каенлы авыл җирлеге сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гарипов